КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2021 ел, 31 май г.Казань № 399

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Юридик затларга сәламәтлек саклау өлкәсендә чаралар (семинарлар, форумнар, конгресслар, конференцияләр, киңәшмәләр, симпозиумнар, съездлар, тренинглар, саммитлар) үткәрүгә бәйле булган чыгымнарны каплау өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2015 ел, 21 гыйнвар, 27 нче карары белән расланган Юридик затларга сәламәтлек саклау өлкәсендә чаралар (семинарлар, форумнар, конгресслар, конференцияләр, киңәшмәләр, симпозиумнар, съездлар, тренинглар, саммитлар) үткәрүгә бәйле булган чыгымнарны каплау өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибенә үзгәреш кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Юридик затларга сәламәтлек саклау өлкәсендә чаралар (семинарлар, форумнар, конгресслар, конференцияләр, киңәшмәләр, симпозиумнар, съездлар, тренинглар, саммитлар) үткәрүгә бәйле булган чыгымнарны каплау өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2015 ел, 21 гыйнвар, 27 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2016 ел, 20 гыйнвар, 25 нче; 2017 ел, 21 март, 167 нче; 2017 ел, 29 декабрь, 1113 нче карарлары белән кертелгән

үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Юридик затларга сәламәтлек саклау өлкәсендә чаралар (семинарлар, форумнар, конгресслар, конференцияләр, киңәшмәләр, симпозиумнар, съездлар, тренинглар, саммитлар) үткәрүгә бәйле булган чыгымнарны каплау өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибенә, аны яңа редакциядә (карарга теркәлә) бәян итеп, үзгәреш кертергә:

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2021 ел, 21 май, 27 нче
карары белән расланды
(Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2021 ел, 31 май, 399 нчы
карары редакциясендә)

Юридик затларга сәламәтлек саклау өлкәсендә чаралар (семинарлар, форумнар, конгресслар, конференцияләр, киңәшмәләр, симпозиумнар, съездлар, тренинглар, саммитлар) үткәрүгә бәйле булган чыгымнарны каплау өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү
тәртибе

1. Бу Тәртип Россия Федерациясе Бюджет кодексы, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Юридик затларга, индивидуаль эшмәкәрләргә, шулай ук товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр җитештерүче физик затларга субсидияләр, шул исәптән субсидияләр рәвешендә грантлар бирүне җайга сала торган норматив хокукый актларга, муниципаль хокукый актларга карата гомуми таләпләр турында һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актлары һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларындагы аерым нигезләмәләре үз көчен югалткан дип тану турында» 2020 елның 18 сентябрендәге 1492 номерлы карары, Татарстан Республикасы Бюджет кодексы нигезендә эшләнгән һәм сәламәтлек саклау өлкәсендә хезмәткәрләрнең һөнәри компетенцияләрен арттыруга юнәлдерелгән чаралар (семинарлар, форумнар, конгресслар, конференцияләр, киңәшмәләр, симпозиумнар, съездлар, тренинглар, саммитлар) үткәрүгә бәйле чыгымнарны каплау өчен юридик затларга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр (алга таба – субсидия) бирү механизмын билгели.

3. Субсидия тиешле финанс елына субсидия бирү өчен бюджет акчасын алучы буларак Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгына (алга таба – Министрлык) билгеләнгән тәртиптә җиткерелгән бюджет йөкләмәләре лимитлары чикләрендә бирелә.

1.3. Субсидия турындагы мәгълүматлар Министрлык тарафыннан «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Россия Федерациясе бюджет системасының бердәм порталында (алга таба – бердәм портал) «Бюджет» бүлегендә урнаштырыла.

3. Субсидияләр сәламәтлек саклау өлкәсендә хезмәткәрләрнең һөнәри компетенцияләрен арттыруга юнәлдерелгән чаралар (семинарлар, форумнар, конгресслар, конференцияләр, киңәшмәләр, симпозиумнар, съездлар, тренинглар, саммитлар) (алга таба – чаралар) үткәрүгә бәйле булган, расланган чыгымнарны каплау өчен Татарстан Республикасы территориясендә эшчәнлеген гамәлгә ашыручы теләсә кайсы оештыру-хокук формасындагы юридик затларга (дәүләт (муниципаль) учреждениеләреннән тыш) бирелә.

4. Субсидия алучыны сайлап алуны үткәрү тәкъдимнәр соратып алу юлы белән башкарыла. Сайлап алу, сайлап алуда катнашучының сайлап алу критерийларына һәм сайлап алуда катнашуга тәкъдимнәр (заявкалар) керү чиратына туры килүеннән чыгып, сайлап алуда катнашучы өчен сайлап алуда катнашучылар тарафыннан җибәрелгән тәкъдимнәр (заявкалар) нигезендә үткәрелә.

5. Министрлык, сайлап алуны үткәрү срогы башланганга кадәр өч календарь көннән дә соңга калмыйча, бердәм порталда һәм үзенең «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында (https://minzdrav.tatarstan.ru/) (алга таба – рәсми сайт) сайлап алуны үткәрү турында белдерү урнаштыра. Тәкъдимнәрне (заявкаларны) кабул итү бердәм порталда һәм рәсми сайтта сайлап алуны үткәрү турында белдерү урнаштырган көннең икенче көненнән соң календарь көннәрдә исәпләнә торган 30 көн эчендә гамәлгә ашырыла.

Сайлап алуны үткәрү турындагы белдерүдә түбәндәгеләр күрсәтелә:

сайлап алуны үткәрү сроклары (сайлап алуда катнашучыларның тәкъдимнәрен (заявкаларын) тапшыра (кабул итә) башлау (тапшырып (кабул итеп) бетерү) датасы һәм вакыты);

субсидия бирү максатлары;

сайлап алуны үткәрү шартлары;

субсидия бирү нәтиҗәләре;

Министрлыкның исеме, аның урнашу урыны, почта адресы, электрон почта адресы;

сайлап алуны үткәрү тәэмин ителә торган «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә сайтның домен исеме, һәм (яки) челтәр адресы, һәм (яки) битләр күрсәткечләре;

бу Нигезләмәнең 7 пункты нигезендә сайлап алуда катнашучыларга карата таләпләр һәм сайлап алуда катнашучылар тарафыннан аларның әлеге таләпләргә туры килүен раслау өчен тапшырыла торган документлар исемлеге;

сайлап алуда катнашучылар тарафыннан тәкъдимнәр (заявкалар) бирү тәртибе һәм бу Тәртипнең 8 пунктындагы икенче абзацы нигезендә сайлап алуда катнашучылар тарафыннан бирелә торган тәкъдимнәрнең (заявкаларның) формасына һәм эчтәлегенә карата куела торган таләпләр;

сайлап алуда катнашучыларның тәкъдимнәрен (заявкаларын) кире алу тәртибе, сайлап алуда катнашучыларның тәкъдимнәрен (заявкаларын) кире кайтару (шул исәптән сайлап алуда катнашучыларның тәкъдимнәрен (заявкаларын) кире кайтару өчен нигезләрне билгели торган) тәртибе, сайлап алуда катнашучыларның тәкъдимнәренә (заявкаларына) үзгәрешләр кертү тәртибе;

бу Тәртипнең 10 – 11 пунктлары нигезендә сайлап алуда катнашучыларның тәкъдимнәрен (заявкаларын) карап тикшерү һәм бәяләү кагыйдәләре;

сайлап алуда катнашучыларга сайлап алуны үткәрү турында белдерү нигезләмәләренә аңлатма бирү тәртибе, мондый аңлатмалар бирү срогы башлану һәм тәмамлану датасы;

сайлап алуда җиңүче тарафыннан субсидия бирү турындагы килешүгә (алга таба – килешү) куелырга тиешле имза кую срогы;

сайлап алуда җиңүчене килешү төзүдән баш тарткан дип тану шартлары;

бердәм порталда һәм Министрлыкның рәсми сайтында сайлап алуда җиңүче билгеләнгән көннән соң килә торган 14 календарь көннән дә соң булмаган сайлап алу нәтиҗәләрен урнаштыру датасы.

6. Субсидия алучыларның сайлап алу критерийлары:

бу Тәртипнең 15 пунктында каралган сайлап алуда катнашучы тарафыннан тәкъдим ителгән чараларны оештыру һәм үткәрү чыгымнары сметасының субсидия бирелә торган чыгымнар юнәлешләренә туры килү;

чараларны оештыру һәм үткәрү тәҗрибәсе кимендә өч ел булу;

сайлап алуда катнашучы законнар нигезендә Татарстан Республикасы территориясендә эшчәнлеген сайлап алуны игълан итү датасына кадәр кимендә өч ел гамәлгә ашыра.

7. Субсидияләр сайлап алуны үткәрү турында белдерү урнаштырылган айга кадәрге айның беренә түбәндәге таләпләргә туры килә торган юридик затларга (алга таба – сайлап алуда катнашучы) бирелә:

сайлап алуда катнашучының салымнар һәм җыемнар турында Россия Федерациясе законнары нигезендә түләнергә тиешле салымнар, җыемнар, иминият кертемнәре, пенялар, штрафлар, процентлар түләү буенча үтәлмәгән йөкләмәләре булмаска тиеш;

сайлап алуда катнашучының Татарстан Республикасы бюджетына субсидияләрне, шул исәптән башка хокукый актлар нигезендә бирелгән субсидияләрне, бюджет инвестицияләрен кире кайтару буенча үз вакытында түләнмәгән бурычлары, шулай ук Татарстан Республикасы бюджеты каршында акчалата йөкләмәләр буенча үз вакытында түләнмәгән (җайга салынмаган) башка бурычлары булмаска тиеш;

сайлап алуда катнашучы үзгәртеп оештыру (сайлап алуда катнашкан юридик затка кушу, башка юридик затка кушу формасында үзгәртеп оештырудан тыш), бетерү процессында булмаска, аңа карата банкротлык процедурасы билгеләнмәскә, сайлап алуда катнашучы эшчәнлеге Россия Федерациясе законнарында каралган тәртиптә туктатылмаска тиеш;

дисквалификацияләнгән затлар реестрында дисквалификацияләнгән җитәкче, коллегиаль башкарма орган әгъзалары, бердәм башкарма орган функцияләрен башкаручы зат яки сайлап алуда катнашучының баш бухгалтеры турында мәгълүматлар булмау;

сайлап алуда катнашучы чит ил юридик заты, шулай ук Россия Федерациясе Финанс министрлыгы раслый торган, салым салуның ташламалы салым режимы бирелә торган һәм (яки) мондый юридик затларга карата финанс операцияләрен уздырганда мәгълүмат ачуны һәм бирүне күздә тотмаган дәүләтләр һәм территорияләр (офшор зоналары) исемлегенә кертелгән дәүләт яки территория теркәлү урыны булып торган, устав (җыелма) капиталында чит илләр юридик затларының катнашу өлеше барысы бергә җыеп исәпләгәндә 50 проценттан артмаган Россия юридик заты булмаска тиеш;

сайлап алуда катнашучы бу Тәртипнең 3 пунктында күрсәтелгән максатлар өчен Татарстан Республикасының башка норматив хокукый актлары нигезендә Татарстан Республикасы бюджетыннан акча алмаска тиеш.

8. Субсидия алуга сайлап алуда катнашу өчен сайлап алуда катнашучы Министрлыкка түбәндәге документларны үз эченә алган тәкъдим (заявка) тапшыра:

Министрлык тарафыннан расланган форма буенча заявка;

сайлап алуда катнашучының гамәлгә кую документлары күчермәләре;

сайлап алуда катнашучының җитәкчесе вәкаләтләрен раслый торган документлар күчермәләре;

сайлап алуда катнашучының чараларны оештыру һәм үткәрү чыгымнары сметасын;

сайлап алуны үткәрү турында белдерү урнаштыру датасына чараларны оештыру һәм үткәрүгә бәйле фактта башкарылган чыгымнарны раслый торган документлар күчермәләре: шартнамәләр, түләү йөкләмәләре, накладнойлар, счетлар, счет-фактурлар, башкарылган эшләр актлары, башкарылган эшләр турында сайлап алуда катнашучының вәкаләтле заты тарафыннан таныкланган актлар;

сайлап алуда катнашучының җитәкчесе тарафыннан имза куелган, әлеге чараларны раслый торган документлар теркәлгән чаралар үткәрүдә тәҗрибә турындагы белешмә кәгазе;

сайлап алуда катнашучының җитәкчесе тарафыннан имза куелган бу Тәртипнең 7 пунктында билгеләнгән таләпләргә туры килүе турындагы белешмә кәгазе (ирекле формада);

«Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә сайлап алуда катнашучы турында, сайлап алуда катнашучы тарафыннан бирелә торган тәкъдим (заявка), тиешлеайлап алуга бәйле сайлап алуда катнашучы турында башка мәгълүматны бастырып чыгаруга (урнаштыруга) ризалык.

Документлар сайлап алуда катнашучы тарафыннан кәгазьдә тапшырыла. Чистартулар һәм төзәтүләр рөхсәт ителми, моңа мөһер белән беркетелгән (булган очракта) һәм сайлап алуда катнашучының вәкаләтле заты имзасы белән таныкланган төзәтмәләр керми. Кәгазьдә тапшырылган тәкъдимнәрнең (заявкаларның) барлык битләре сайлап алуда катнашучының вәкаләтле заты имзасы белән таныкланырга тиеш.

Бирелә торган мәгълүматларның дөреслеге өчен сайлап алуда катнашучылар Россия Федерациясе законнары нигезендә җавап бирә.

Сайлап алуда катнашучы заявканы сайлап алу тәмамланганга кадәр теләсә кайсы вакытта кире алырга хокуклы. Сайлап алуда катнашучы, кирәк булганда, заявкалар бирү өчен билгеләнгән срок эчендә заявканы кабат бирергә хокуклы, шул ук вакытта заявка кергән көнендә чират тәртибендә теркәүгә алына.

9. Сайлап алуда катнашучы үз теләге белән Министрлыкка түбәндәге документларны тапшырырга хокуклы:

юридик затны дәүләт теркәвенә алу турында таныклык күчермәсе йә Юридик затларның бердәм дәүләт реестры кәгазенең күчермәсе;

салым органында исәпкә кую турында таныклык күчермәсе;

салым органыннан салымнар һәм җыемнар турында Россия Федерациясе законнары нигезендә түләнергә тиешле салымнар, җыемнар, иминият кертемнәре, пенялар, штрафлар, процентлар түләү буенча үтәлмәгән бурычы булмау турында белешмә;

Юридик затларның бердәм дәүләт реестрыннан өземтә.

Сайлап алуда катнашучы тарафыннан бу пунктта күрсәтелгән документларны тапшырмаган очракта, Министрлык аларны ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек тәртибендә соратып ала.

10. Министрлык:

сайлап алуны үткәрү турындагы белдерүдә билгеләнгән сайлап алуны үткәрү срогы дәвамында тәкъдимнәрне (заявкаларны) алар кергән көнне чират тәртибендә теркәп бара;

сайлап алуны үткәрү турындагы белдерүдә күрсәтелгән сайлап алуны үткәрү срогы тәмамланган көннән эш көннәрендә исәпләнә торган ике көн эчендә аларның сайлап алуны үткәрү турындагы белдерүдә билгеләнгән критерийларга һәм таләпләргә туры килү-килмәвен карап тикшерә, Министрлык боерыгы белән расланган форма буенча сайлап алу нәтиҗәләре турында реестр төзи һәм сайлап алуда җиңүче турында йә заявканы алудан баш тарту турында карар кабул итә;

сайлап алуда җиңүче билгеләнгән көннән соң килә торган 14 календарь көннән дә соңга калмыйча, түбәндәге мәгълүматларны үз эченә алган сайлап алу нәтиҗәләре турындагы мәгълүматны бердәм порталда һәм Министрлыкның рәсми сайтында урнаштыра:

заявкаларны карап тикшерүне үткәрү датасы, вакыты һәм урыны;

заявкалары карап тикшерелгән сайлап алуда катнашучылар турында мәгълүмат;

заявкалары кабул итүдән баш тартылган сайлап алуда катнашучылар турында мәгълүмат (аларны кабул итүдән баш тарту сәбәпләрен күрсәтеп), шул исәптән сайлап алуны үткәрү турындагы белдерүнең мондый заявкалар туры килми торган нигезләмәләре;

сайлап алуда җиңүче исеме (алга таба – субсидия алучы) һәм аңа бирелә торган субсидия күләме.

Сайлап алуда катнашу өчен бер тәкъдим (заявка) дә тапшырылмаган очракта, сайлап алу уздырылмаган дип таныла.

11. Министрлык тарафыннан сайлап алуда катнашучының тәкъдимнәрен (заявкаларын) карап тикшерү стадиясендә аларны алудан баш тарту өчен түбәндәгеләр нигез була:

сайлап алуда катнашучының бу Тәртипнең 7 пунктында билгеләнгән таләпләргә һәм бу Тәртипнең 6 пунктында каралган сайлап алу критерийларына туры килмәве;

сайлап алуда катнашучы тарафыннан тәкъдим ителгән тәкъдимнәрнең (заявкаларның) һәм документларның сайлап алуны үткәрү турындагы белдерүдә билгеләнгән таләпләргә туры килмәве;

сайлап алуда катнашучы тарафыннан бирелгән мәгълүматның, шул исәптән юридик затның урнашу урыны һәм адресы турындагы мәгълүматның дөрес булмавы;

сайлап алуда катнашучының тәкъдимнәр (заявкалар) бирү өчен билгеләнгән датадан һәм (яки) вакыттан соң тәкъдим (заявка) бирүе;

бюджет йөкләмәләре лимитларының булмавы.

12. Министрлык, бердәм порталда һәм Министрлык рәсми сайтында сайлап алу нәтиҗәләре турында мәгълүмат урнаштырган көннән биш эш көненнән дә соңга калмыйча, Министрлык боерыгы белән рәсмиләштерелә торган субсидия алучыга субсидия бирү турында карар кабул итә.

13. Субсидия бирү килешү нигезендә гамәлгә ашырыла. Килешү Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан расланган бертип форма нигезендә субсидия бирү турында карар кабул ителгән көннән эш көннәрендә исәпләнә торган ике көн эчендә төзелә.

Килешүдә түбәндәгеләр карала:

субсидия күләме, аның максатчан билгеләнеше;
аны күчерү тәртибе һәм сроклары;
субсидия бирү нәтиҗәләренең мәгънәләре;
каплау өчен субсидия бирелә торган чыгымнар юнәлеше;
моңа кадәр җиткерелгән, бу Тәртипнең 2 пунктында күрсәтелгән бюджет йөкләмәләре лимитларын Министрлыкка субсидияне килешүдә билгеләнгән күләмдә биреп булмауга китерә торган дәрәҗәдә киметкән очракта, килешүнең яңа шартларын килештерү турында яки яңа шартлар буенча уртак фикергә ирешеп булмаганда килешүне өзү турында шарт;
Министрлык һәм дәүләт финанс контроле органнары тарафыннан субсидия алучының субсидия бирү шартларын, максатларын һәм тәртибен үтәвенә тикшерүләрне гамәлгә ашыруга субсидия алучының ризалыгы;
Кирәк булганда Министрлык белән субсидия алучы Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән бертип формалар нигезендә килешүгә өстәмә килешү, шул исәптән килешүне өзү турында өстәмә килешү төзи.
14. Министрлык субсидия бирү турында карар кабул ителгән көннән эш көннәрендә исәпләнә торган 10 көн эчендә субсидияне үзенең Татарстан Республикасы Финанс министрлыгында ачылган шәхси счетыннан субсидия алучы өчен Россия Федерациясе Үзәк банкы яки кредит оешмасы учреждениеләрендә ачылган исәп-хисап яки корреспондентлык счетына күчерә.
15. Субсидия бирелә торган чараларны оештыруга һәм үткәрүгә чыгымнар юнәлешләре:
чаралар үткәрү өчен урыннарны һәм җиһазларны арендалау чыгымнары;
канцелярия, хуҗалык товарлары, сувенир продукция сатып алу чыгымнары;
стенд ясау һәм аны җиһазлау чыгымнары (шул исәптән монтажлау-демонтажлау хезмәтләре, инженерлык-техник хезмәтләре);
реклама-презентация материаллары һәм хезмәтләр чыгымнары;
залларны бизәү хезмәтләре, фотога һәм видеога төшерү, чәчәкләр сатып алу чыгымнары;
тәрҗемәчеләр хезмәтләре өчен түләү чыгымнары;
концерт программасы өчен түләү чыгымнары;
транспорт хезмәтләре чыгымнары;
туклануны, экскурсия хезмәте күрсәтүне оештыру чыгымнары;
ашыгыч медицина ярдәме бригадаларының кизү торулары өчен түләү чыгымнары;
виза ярдәме өчен түләү чыгымнары;
видеотрансляцияләр оештыру һәм сайтлар булдыру чыгымнары;
чараларны оештыру һәм үткәрү өчен гражданлык-хокук шартнамәләре нигезендә, шул исәптән авторлык шартнамәләре нигезендә җәлеп ителгән белгечләрнең хезмәтләре өчен түләү чыгымнары;
чыгым материаллары өчен түләү чыгымнары;
мәгариф программаларын эшләү һәм үткәрү хезмәтләре өчен түләү чыгымнары;
командировка чыгымнары;
Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы салым законнары нигезендә салымнар түләү чыгымнары.
16. Бирелә торган субсидия күләме (С) түбәндәге формула буенча билгеләнә:

$$С = З_1 + З_2 + ... + З_n,$$

монда:

$З_1$, $З_2$, ..., $З_n$ – бу Тәртипнең 15 пунктында күрсәтелгән юнәлешләр буенча чыгымнар суммалары.

Бу Тәртипнең 15 пунктындагы икенче – уналтынчы абзацларында күрсәтелгән чыгымнар юнәлешләре Министрлык тарафыннан бердәй (бертөрле) товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләрнең базар бәяләре турындагы мәгълүматны, шул исәптән җитештерүче оештыручыларның бәяләре турындагы, дәүләт статистикасы органнарында, шулай ук массакүләм мәгълүмат чараларында һәм махсус әдәбиятта (җитештерүчеләрнең һәм тәэмин итүчеләрнең «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтларын кертеп) булган бәяләр дәрәҗәсе турындагы мәгълүматны анализлаудан гыйбарәт чагыштырма базар бәяләре (базар анализы) ысулы белән, шулай ук Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан билгеләнгән чит ил делегацияләрен, чит илләргә карамаган делегацияләрне, аерым затларны кабул итүгә һәм аларга хезмәт күрсәтүгә акча сарыф итү нормаларын исәпкә алып билгеләнә торган чыгымнар күләме.

Бу Тәртипнең 15 пунктындагы унҗиденче һәм унсигезенче абзацларында күрсәтелгән чыгымнар юнәлешләре, Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнарын исәпкә алып, Министрлык тарафыннан билгеләнә.

17. Субсидия бирү нәтиҗәләре:

субсидия бирелгән елның 31 декабренә кадәр субсидия бирелә торган чараны үткәрү – кимендә 1;

субсидия бирелгән елның 31 декабренә кадәр субсидия бирелә һәм үткәрелә торган чарада катнашучы ягыннан шикаятьләр саны – 0.

18. Субсидия алучы, субсидия бирелгән елдан соң килә торган елның 30 эш көненнән дә соңга калмыйча, Министрлыкка Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән килешүнең бертип формасында билгеләнгән форма буенча субсидия бирү нәтиҗәләренә ирешү турында хисап тапшыра.

19. Субсидия, субсидияләр алучылар тарафыннан субсидия алу өчен дөрес булмаган мәгълүматлар һәм документлар тапшырылган, субсидия алучылар тарафыннан субсидияләр биргәндә билгеләнгән, шул исәптән Министрлык һәм дәүләт финанс контроле органнары тарафыннан үткәрелгән тикшерүләр фактлары буенча ачыкланган бозулар булган очракларда, шулай ук бу Тәртипнең 17 пунктында күрсәтелгән субсидия бирү нәтиҗәләре күрсәткечләренә ирешмәгән очракта, субсидия алучы тарафыннан Министрлыкның тиешле таләбе алынган көннән эш көннәрендә исәпләнә торган 30 көн эчендә Татарстан Республикасы бюджетына кире кайтарылырга тиеш.

20. Субсидияне кире кайтару срогы бозылганда Министрлык срок чыккан көннән эш көннәрендә исәпләнә торган җиде көн эчендә әлеге акчаны Татарстан Республикасы бюджетына бюджет законнарында билгеләнгән тәртиптә түләтү буенча чаралар күрә.

Әлеге акчаны Татарстан Республикасы бюджеты керемена ирекле рәвештә кире кайтарудан баш тартылган очракта, алар Россия Федерациясе законнары нигезендә мәҗбүри тәртиптә түләтелергә тиеш.

21. Министрлык һәм дәүләт финанс контроле органнары субсидия алучы тарафыннан субсидия бирү шартлары, максатлары һәм тәртибе үтәлешен мәҗбүри тикшерүне гамәлгә ашыра.

22. Субсидия акчасын максатчан һәм нәтиҗәле файдалануны тикшерүдә тоту Министрлык тарафыннан гамәлгә ашырыла.

_______________________________